**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «28» апреленнән № 138

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Кызыл Октябрь авыл җирлегенең генераль планын әзерләү турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 24, 25 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясы нигезендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Кызыл Октябрь авыл җирлегенең генераль планы проектын әзерләүгә керешергә.

2. Проектны эшләү вакытын билгеләргә - 6 ай.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Кызыл Октябрь авыл җирлеге башлыгы – Захаров Владимир Владимировичка физик һәм юридик затларның проектны әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми порталына //pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә

муниципаль районының рәсми сайтына http://novosheshminsk.tatarstan.ruурнаштырылырга тиеш .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов